# ФИГЫЛЬ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ
# (ЗАЛОГИ ГЛАГОЛА)

| Залоги | Аффиксы | Примеры |
|---|---|---|
| Действитель-ный (төп) | – | *Бала идән юа (Ребёнок моет пол).* |
| Страдатель-ный (төшем) | *-л/-ыл/-ел*<br>*-н/-ын/-ен*<br>*(к словам на -ла/-лә/-л)* | *Идән (бала тарафыннан) ю-ыл-а (Пол моется (ребёнком)).* |
| Возвратный (кайтым) | *-н/-ын/-ен* | *Бала ю-ын-а (Ребёнок моется).* |
| Взаимно-совместный (уртаклык) | *-ш/-ыш/-еш* | *Бала идән ю-ыш-а (Ребёнок по-могает мыть пол).* |
| Понудитель-ный (йөкләтү) | *-т/-тыр/-тер*<br>*-дыр/-дер*<br>*-гар/-гәр*<br>*-кар/-кәр*<br>*-гыр/-гер*<br>*-кыр/-кер*<br>*-гыз/-гез*<br>*-кыз/-кез* | *аша-т (корми), әйт-тер (за-ставь сказать)*<br>*Бала идән ю-дыр-а (Ребёнок на кого-то возлагает мытьё пола).*<br>*үт-кәр (проводи (мероприятие))*<br>*җит-кер (доводи (до конца))*<br>*мен-гез (поднимай), а(к)-гыз (дай стечь)* |

## ТӨШЕМ ЮНӘЛЕШЕ
## (СТРАДАТЕЛЬНЫЙ ЗАЛОГ)

- В страдательном залоге действие, о котором идет речь, совершается не подлежащим, а другим субъектом. Например: *Идән юыла - пол моется.*
- Глаголы страдательного залога образуются:

а) при помощи аффиксов *-ын/-ен,-н* (глаголы, основы которых оканчиваются на -л или на *ла)*. Например: *Кал - калына, башла - башлана;*

- б) при помощи аффиксов *-ел/-ыл, -л* (глаголы, основы которых оканчиваются на гласный или на один из остальных согласных). Например: *Кара - карала,*

*яз - языла.*

.

Төшем юнәлеше.

Боерык фигыльләрдән төшем юнәлешендәге фигыльләр ясап язысыз.

Ү р н ә к : *Ю - юыл, юыла (моется)*.

а) Ыргыт, яз, өйрән, өйрәт, ки, күтәр, ват, бир, оныт, уян, кер, ар, чакыр, чистарт, ярат, пешер, ишет, бәр, ач, яп, тап.

ә) Бизә, укы, тукта, буя, борчы, сана, төзе.

б) Кал, сал, ал, бел, кил.

Телдән тәрҗемә итегез.

- Төрле фәннәр өйрәтелә; заманча биналар төзелә; кунаклар алдан чакырылган; матур яшәлгән; күп төрле яшелчәләр үстерелә; зур уңыш җыелды; үләннәр тапталган; чәчләр кыска киселгән.

Нокталар урынына тиешле фигыльләр куеп языгыз.

1. Тавыш кайдан ... ?
2. Бу китап кайчан ... ?
3. Бәйрәмгә барлык ветераннар да ... ?
4. Өстәлгә чәчәкләр ... ?
5. Студентларга сораулар күп ... ?

- *чакырылганмы*
- *биреләчәкме*
- *язылган*
- *ишетелә*
- *куелганмы*

Тәрҗемә итегез. Төшем юнәлешендәге фигыльләрне табыгыз.

1) Җил чыкты, тузан күтәрелде, күзгә берни дә күренми башлады.
2) Бу кешенең миңа йөзе таныш, ә менә исеме онытылган инде.
3) Йорт хуҗасына бик күп җылы сүзләр әйтелде, яхшы теләкләр теләнелде һәм бүләкләр бирелде.
4) 1969 нчы елда Чаллы шәһәрендә КамАЗ төзелә башлаган.
5) Сабантуй көнне мәйданда озак йөрелде, шуңа күрә бик арылган иде.
6) Археологлар Кремльдә инде күп еллар казу эшләре алып баралар, һәм биредә борынгы савыт-сабалар табылды.
7) Балалары озак кайтмагач, ата-аналар бик нык борчылдылар.

Җөмләләрне тәрҗемә итегез. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең мәгънәләрен чагыштырыгыз.

- 1) Балалар үзләре матур уенчыклар ясадылар һәм чыршынны **бизәделәр**. - Чыршы да **бизәлде,** инде Яңа елга да күп калмады.
- 2) Савыт-саба юганда, мин ялгыш чынаякны **ваттым**.- Савыт-саба юганда, әниемнең чынаягы ялгыш **ватылды**.
- 3) Капканы ябарга онытма, ачык **калдырма**.- Капка ябылдымы, ачылып **калмадымы**?
- 4) Әтием иртәгәге бәйрәмгә кунаклар **чакырып кайтты**.- Иртәгәге бәйрәмгә киләсе кунакларның барысы да **чакырылдымы**?

Нокталар урынына җәяләр эчендә бирелгән фигыльләрнең тиешлесен куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1) Сәгатьне миңа таба *борып* куй әле. Артыгызга ... карагыз әле, беркем дә юкмы?

2) Пешмәгән җиләкләрне ... , алар әле тәмле түгел. Җебем ... дә эшемнән туктадым.

3) Тәрәзәләрне ... , бүлмәләрне җилләтергә кирәк. Тәрәзәләр җил белән ... , ябарга кирәк.

*(Өз - өзел, бор - борыл, ач - ачыл.)*

Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльләрнең мәгънәләрен чагыштырыгыз.

а) Мин быел капкабызны үзем буядым. Капкабыз зәңгәргә буялган. Әнисеннән күреп, кечкенә Наилә дә иннек белән буянган.

ә) Мин бүлмәдә тузанны көн саен сөртергә тырышам. Ашханәдәге өстәлләр чиста чүпрәк белән сөртелергә тиеш. Бу сөлге юеш, икенче сөлге белән сөртенергә кирәк.

б) Бу майлы тәлинкәләрне кайнар су белән юарга кирәк. Бүлмәдә идән көн саен юылырга тиешме? Син авырыйсың, шуңа күрә хәзергә салкын су белән юынырга ярамый.

Нокталар урынына җәяләр эчендә бирелгән фигыльләрнең тиешнлесен куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

а) Алсу бүген беренче тапкыр үзенең кулъяулыгын .... Бенренче тапкыр гына юса да, Алсуның кулъяулыгы чиста ... . Алсу башта кулъяулыгын юган, аннан соң үзе дә ... .

*(Юынган, юган, юылган.)*

ә) Минем энемне математика укытучысы гел ... . Күрше апаның тәмле пироглары һәр табында .... Наил еш ... , шуңа күрә аның иптәшләре күп түгел.

*(Мактана, мактала, мактый.)*

б) Безнең бакчада түтәлләрне һәрвакыт әтием .... Әле җир юеш, шуңа күрә авыр .... Минем дәү әтием җәй көне шәһәрдә яшәми, айлар буе бакчада ....

*(Казый, казына, казыла.)*

Нокталар урынына җәяләр эчендә бирелгән фигыльләрнең тиешлесен куеп языгыз.

1) Болын никтер күңелсез, үләннәр ... , чәчәкләр ... кебек ... миңа.

2) Каникуллар бетеп бара икән, көннәр үткәне ... дә.

3) Урам буенча йортлар ... , зифа каеннар шаулап утыра.

4) Язгы эшләр беткән, бәрәңгеләр..., басу-кырлар яңгыр көтеп ята.

*(күренде, тезелгән, егылган, утыртылган, тапталган, сизелмәде.)*

| Төп юнәлеш | Төшем юнәлеше |
|---|---|
| Төзүчеләр йорт төзиләр.<br><br>Гөбәдия пешерер өчен Рәмзия дөге ала.<br><br>Алексей татар теленнән тәрҗемә иткәндә сүзлек куллана.<br><br>Укытучы ишекне яба.<br><br>Зөлфия апа этен Актырнак дип атый. | Йорт өч ел төзелә (төзүчеләр тарафыннан).<br><br>Кыяр салаты өчен яшел кыяр алына (ясаучы тарафыннан).<br><br>Татар теле сәяси-иҗтимагый өлкәдә аз кулланылган (кешеләр тарафыннан).<br><br>Совет чорында татар мәктәпләре ябыла (дәүләт тарафыннан).<br><br>19 нчы гасырда бөтен төрки халыклар «татар» дип аталалар (европалылар тарафыннан). |
| Субъектлар: төзүчеләр, Рәмзия, Алексей, укытучы, Зөлфия апа. | Объектлар: йорт, кыяр, татар теле, мәктәпләр, төрки халыклар. |